КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль г.Казань № 169

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитар-эпидемиологик хәлне һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 февраль, 136 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2022 елның 28 февраленнән гражданнар катнашында массакүләм чаралар үткәрү, әгәр әлеге карар белән башкасы билгеләнмәгән булса.»;

6 пунктның «е» пунктчасында «, гражданнар катнашында башка массакүләм чаралар үткәрү, әгәр әлеге карар белән башкасы билгеләнмәгән булса» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 9 пункт өстәргә:

«9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы территориясеннән китәргә мәҗбүр булган һәм Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча урнаштырыла торган COVID-19 коронавирус йогышлы авыруына тест үткәрүне тәэмин итәргә.».

2. Бу карар 2022 елның 28 февраленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин